ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.06.2022 № 838

Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында

Алабуга муниципаль районының «Атказанган спорт мастеры», «Халыкара класслы спорт мастеры», «Спорт мастеры», «Спорт мастерлыгына кандидат» исемнәрен алган, иң яхшы спортчыларына адреслы ярдәм күрсәтү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турындагы Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия составын төзергә һәм расларга (2 нче кушымта).
3. Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия турындагы Нигезләмәне расларга (3 нче кушымта).
4. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендияләрен финанслауны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының агымдагы финанславы исәбенә карауны тәкъдим итәргә.
5. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында» 2022 елның 11 мартындагы 245 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Л. Р. Яһудинга йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.06.2022 838 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү турында**
**Нигезләмә**

1. Алабуга муниципаль районы Башлыгының стипендиясе (алга таба - стипендия) «Атказанган спорт мастеры», «Халыкара классны спорт мастеры», «Спорт мастеры», «Спорт мастерлыгына кандидат» исемнәрен алган, иң яхшы спортчыларга адреслы ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлгә ашырыла.
2. «Атказанган спорт мастеры», «Халыкара классны спорт мастеры», «Спорт мастеры», «Спорт мастерлыгына кандидат» исемнәрен алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү комиссия карары нигезендә (алга таба текст буенча - Комиссия) билгеләнә.
3. Адреслы стипендияне ай саен түләү Алабуга муниципаль районы Башлыгы комитетының агымдагы календарь ел ахырына кадәр 25 көннән дә соңга калмыйча башкарыла.
4. Дәгъва кылучылар исемлеге Алабуга муниципаль районы спорт мәктәпләре тәкъдименнән чыгып төзелә.
5. Стипендияләр билгеләү өчен критерийлар әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында китерелә.
6. Алабуга муниципаль районының спорт мәктәпләрендә спорт исемен алган тәрбияләнүчеләр стипендия алуга дәгъва кылучылар була ала.
7. Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен алу өчен, спорт исемен бирү турында раслаучы документ алган көннән алып 1 ай эчендә түбәндәге документларны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторына дәгъва кылучылар исеменнән түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:
   Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга
   муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә:

- стипендия билгеләү өчен дәгъва кылу турында белешмәләр (әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта);
- спорт исеме бирелүне раслаучы документның күчермәсе;
- паспорт күчермәсе;
- Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык күчермәсе (ИНН);

- мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе (СНИЛС), яисә индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәп системасында теркәлүне раслый торган һәм шәхси иминият счетының иминият номеры турында белешмәләр;
- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

Тәкъдим итүне (үтенечнамәне Алабуга муниципаль районының спорт мәктәбе директоры (җитәкчесе) әзерли һәм имзалый.

Документларны алган көннән 5 эш көне эчендә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы дәгъва кылучылар турында фикер алышу һәм аны раслау өчен Комиссиягә җибәрә.

8. Кандидатлар турында фикер алышу һәм раслау комиссия утырышында башкарыла. Комиссия әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны алган көннән алып 7 эш көне эчендә карый. Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү, яисә стипендия билгеләүдән баш тарту турында комиссия карары беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

9. Спортчыга стипендия бирүдән баш тарту өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

- әлеге нигезләмәнең 7 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау).

10. Комиссия утырышын уздыру датасыннан комиссия утырышы беркетмәсе нигезендә 5 эш көне эчендә, комиссия стипендия түләү турындагы хатны Палатага җибәрә.

11. Стипендия агымдагы календарь ел ахырына кадәр Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясе билгеләнгән датадан түләнә. Календарь ел ахырында түләү комиссия беркетмәсе нигезендә туктатыла. Түләүне туктату турындагы беркетмә җиде эш көне эчендә комиссия утырышын уздыру датасыннан Палатага җибәрелә.

12. Стипендиат, комиссия карары буенча, Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясеннән вакытыннан алда түбәндәге очракларда мәхрүм ителергә мөмкин:

- Алабуга муниципаль районының спорт мәктәпләре боерыгы нигезендә Алабуга муниципаль районы спорт мәктәбеннән спортчыны чыгару;
- РФ Спорт министрлыгы һәм ТР Спорт министрлыгы боерыгы нигезендә спортчы исеменнән мәхрүм итү.

13. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы боерыкны алган көннән алып 5 эш көне эчендә, комиссия каравына стипендияне вакытыннан алда мәхрүм итү турында үтенеч җибәрә.

14. Вакытыннан алда стипендиядән мәхрүм итү турында үтенеч алган көннән алып 7 эш көне эчендә, комиссия беркетмә тарафыннан рәсмиләштерелә торган спортчының стипендиясен мәхрүм итү турында карар кабул итә. Вакытыннан алда стипендиядән мәхрүм итү турында

комиссия утырышы беркетмәсе «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә (алга таба - Палата) комиссия утырышын уздыру датасыннан 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Мондый спортчыга стипендия түләве шундый бер айдан туктатыла, комиссия аны Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясеннән мәхрүм итү турында карар кабул итә.

Спорт исеме алган, иң яхшы
спортчыларга Алабуга
муниципаль районы Башлыгы
стипендиясен билгеләү турындагы
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

**Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү өчен критерийлар**

| | Бирелгән исем | Стипендияләр күләме мең сум/аена |
|---|---|---|
| 1. | «Атказанган спорт мастеры» | 10 000,0 |
| 2. | «Халыкара класслы спорт мастеры» | 5 000,0 |
| 3. | «Спорт мастеры» | 3 000,0 |
| 4. | «Спорт мастерлыгына кандидат» | 1 000,0 |

Спорт исеме алган,
иң яхшы спортчыларга Алабуга
муниципаль районы Башлыгы
стипендиясен билгеләү турындагы
Нигезләмәгә 2 нче кушымта

Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга
муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә
дәгъва кылучы турында белешмәләр

| Дәгъва кылучының Ф.И.А.и. | (чч.мм.гг.) Туу датасы | Адресы | Спорт мәктәбенең аталышы | Дәгъва кылучының куйган казанышлары турында кыскача белешмә |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

Спорт мәктәбе директоры____________________________(Ф.И.А.и.)
(Имза)

МУ

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.06.2022 838 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия составы

| Ф.И.А.и. | Вазифасы |
|---|---|
| Яһудина Л.Р. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе |
| Деготьков Р.А. | - «Спорт корылмалары дирекциясе» МАУ директоры, комиссия рәисе урынбасары |
| Маркина И.Ю. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының спортны үстерү секторы баш белгече, комиссия секретаре |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Садыйкова Э.И. | - Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Шалаумова Н.П. | - Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы (килешү буенча) |
| Балобанов К.Г. | -Алабуга муниципаль районының «1 нче спорт мәктәбе» МБУ директоры (килешү буенча) |
| Галимов И.Г. | -Алабуга муниципаль районының «2 нче спорт мәктәбе» МБУ директоры (килешү буенча) |
| Денисенко Д.Б. | - Алабуга муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» МБУ директоры (килешү буенча) |
| Немтырев А.М. | - Алабуга муниципаль районының «Юность» спорт мәктәбе» МБУ директоры (килешү буенча) |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
30.06.2022 838 номерлы
карарына 3 нче кушымта

**Спорт исеме алган, иң яхшы спортчыларга Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләү буенча комиссия турында Нигезләмә**

1. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.
2. Комиссиянең төп бурычы – спорт исемен алган, иң яхшы спортчыларына Алабуга муниципаль районы Башлыгы стипендиясен билгеләүгә дәгъва кылучының материалларын, документларын карау.
3. Комиссия составы – 9 кешедән төзелә: комиссия рәисе, аның урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссия әгъзалары составында төзелә. Комиссия эшчәнлеге белән аның рәисе җитәкчелек итә.

Комиссия әгъзалары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;
2) комиссия рәисенә утырышны кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;
3) комиссия утырышында катнашырга;
4) комиссия тарафыннан карауга чыгарылган мәсьәләләр буенча фикер алышуда катнашырга;
5) карау өчен чыгарылган мәсьәлә буенча фикерне бәян итәргә.

Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән, шулай ук түбәндәгеләрдән файдалана:

1) комиссия утырышларында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;
2) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларга кул куя.

Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаганда башкара.

Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән, шулай ук түбәндәгеләрдән файдалана:

1) комиссия эшен алып бара;
2) комиссия утырышларына материаллар әзерләүне оештыра;
3) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмат материаллары белән тәэмин итә;
4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара

4. Комиссия утырышы стипендия билгеләү мәсьәләләрен карауга материаллар кергән саен, әмма әлеге нигезләмәнең 7 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән ун эш көненнән дә соңга калмыйча уздырыла. Комиссия утырышын Комиссия рәисе йә ул булмаган очракта, Комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5. Комиссия утырышы, әгәр комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзалары үз хокукларын өченче затларга, шулай ук комиссия әгъзалары булган затларга тапшырырга хокуклы түгел. Комиссия карарлары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән комиссиянең ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана.

6. Комиссия карары тапшырылган документларны карау һәм түләүләр бирү нигезләмәсенең таләпләргә туры килү нәтиҗәләре буенча ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, әгәр алар өчен комиссия әгъзаларының гомуми санының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

7. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

8. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.